**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Елаур ав. КАРАР

«10» ноябрь 2022 ел № 6

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Сосновка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 21 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Сосновка авылында түбәндәге адрес буенча: Сосновка авылы, Центральная урамы, 19 йорт адресы буенча, Үзәк урамы 1 нче йорттан 27 нче йортка кадәр, Кирпичное авылы Тынычлык урамы 3нче йорттан 15нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2023 елда Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән ризамы:
Сосновка торак пункты чикләрендә авыл эчендәге җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау (юл катламын күтәрү, ташу, таш җәю, транспорт хезмәтләре күрсәтү);
«РИЗА» «КАРШЫ»

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Сосновка авылында 24.10.2022 елдан 2нче номерлы Гражданнар Җыены карарының үз көчен югалтуын тану турында;
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сосновка авылы торак пунктында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында " 24.10.2022 ел, № 1 карарның үз көчен югалтуын тану хакында.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат

муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының Сосновка торак пунктының мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

4. Бу карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В. Охотникова